ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы законнарының торышы турында нотык әзерләү тәртибе хакында» 2010 елның 4 мартындагы 709-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы законнарының торышы турында нотык әзерләү тәртибе хакындагы нигезләмәнең 5 пунктына, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырып, «Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә (2016 елның 21 июнендәге 1296-V ДС номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 1545-V ДС номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 98-VI ДС номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге 365-VI ДС номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 1192-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе,» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты,» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе,» сүзләренә алмаштырырга;

4) 19 пунктта «Парламент хәбәрләре»н нәшер итү эшен оештыра,» сүзләрен «Парламент хәбәрләре» бюллетенен төзи һәм Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыра,» сүзләренә алмаштырырга;

5) 23 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

3. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округындагы эше турында мәгълүмат тапшыру тәртибе хакында» 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына кушымтага (2014 елның 14 апрелендәге 3473-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары нигезендә кертелгән үзгәреш белән), 9 нчы юлны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| «9. | Гражданнарның Татарстан Республикасы Рәисе, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләре адресына тәкъдимнәре». | |

4. «Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 1554-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1 пунктта «ведомствосы» сүзен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары структурасына керә торган Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6.3 пунктта «яисә аның (аларның) аерым нигезләмәләренең» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 7.16 пунктның бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 9.5 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 10.35 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 июне
№ 1975-VI ДС